Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге
Яңа Сарайлы авылы
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«21» ноябрь, 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Әҗмәкәй авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елда  елда Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа Сарайлы авылында яшәү урыны буенча Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа Сарайлы авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлар һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, Әфганстанда, Чечняда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, Чернобыль атом электростанциясендә аварияне ликвидацияләүчеләр-чернобыльчеләр, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 750 (җиде йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы:

- су челтәрләрен проектлау;
- электроматериаллар сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру

Әҗмәкәй авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә

2. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа Сарайлы авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа Сарайлы авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгы М.Г.Фазылҗанов